

**Хатирәләр яңарганда.**

Җиңү көне якынлашкан саен хәтердә ветераннарны барлый башлыйбыз. Туган ил бәхете өчен көрәшкән ветераннарның тормыш тәҗрибәсе белән уртаклашу өчен. Бөек рус адмиралы С.О. Макаровның “Сугышны истә тот!”- дигән сүзләрен искә алып, безгә Бөек Җиңү яулап алган буынның истәлекләрен киләчәк буынга җиткерү изге бурычыбыз. Сүзем безнең Бәзәкә авылында гомер итүче хөрмәтле ветеран Аглиев Зайнак абый турында.
Аглиев Зайнак Әһли улы тумышы белән төп Бәзәкәнеке, 1927 елның 4 маенда туган. Аерым хуҗалыкта иген игеп, мал асрап тормыш иткән әтисе Әһли (1876-1967) белән әнисе - Красный бор районы Салагыш авылы кызы Гафифә (1887-1965), колхозлар оешкач колхозга керәләр. Әтисе гомере буе атлар карый, әнисе төрле эшләр башкара. Гаиләдә 7 бала тәрбияләнә: 1914 елгы Хәдичә, 1916 елгы Рәшидә, 1918 елгы Рәшит, 1922 елгы Кадерле, 1925 елгы Мәхмүдә, 1927 елгы Зайнак, 1932 елгы Суфия. Зайнак сугышка кадәр

мәктәптә укый, җәйләрен әтисе янында атлар карый. Аңа 14 яшь булганда Бөек Ватан сугышы башланып китә. Бу елларда авылдагы карт-коры, хатын-кыз, яшүсмерләр бөтен көчләрен куеп фронт өчен эшлиләр. Ләкин сугыш барган саен колхозларда хәлләр елдан-ел авырлаша бара. Яз җитүгә атларга ашатырга азык булмаганга аларны атауга чыгаралар. Авылның "ат җанлы" 11 яшүсмере белән бергә Зайнак та төнгә аларны сакларга бара. Үсә төшкәч учетчик, ә 8-нче класстан каникул вакытларында үзе ат җигеп эшли. Колхозның Гулливер кушаматлы үгезендә Давлетшин Гәрәй (данлыклы көрәшче Гәрәй Хаҗиенең әтисе) белән Ык Тамагына, Тын тауга, соңрак Алабуга элеваторына икмәк ташыйлар.

1944 елның җәендә 9 классны тәмамлагаган малайларны, шул исәптән Кулячев Фоат белән Аглиев Зайнакны да военный сборга алалар. Соңрак билгеле булганча, Бондюг районыннан 22 егетне, хәрби училищеда укытыр өчен әзерлек төркеменә кушалар. 1944 елның 1 июлендә киткән егетләр Тәтештән 3-4 км ераклыкта урнашкан мәктәптә яшиләр. Бу группа бөтен көнен өйрәнү кырында (учебное поле) үткәрә. Ач, ялангач килеш (көне буе аяк өстендә булуга бернинди чабата чыдамый) көн саен 238 баскыч үтеп Иделгә юынырга төшкәннәрен Зайнак абый бүгенгедәй хәтерли. 40 көннән соң алар яңадан авылга кайталар. Кайту белән колхозда эшкә керешәләр.

1944 елның 27 ноябрендә Бәзәкә авылыннан 12 кешене, шул исәптән Аглиев Зайнакны да армиягә алалар. Бондюг райвоенкоматыннан 12 кешене аерып алып, җәяүләп Әгерже тимер юл станциясенә алып китәләр. Шунда товарный вагоннарга төяп Ульяновск өлкәсе Инза станциясенә китерәләр һәм учебный запасной полкка урнаштыралар. Шулай итеп хәрби хезмәт башлана.

Ләкин, алар тиешле уку программасын үтеп бетерә алмыйлар, яңадан эшелонга төяп каядыр озаталар. Сугыш вакыты законнары кырыс, тәүлекләр буе алар кая барганнарын да белмиләр. Җимерелгән шәһәрләр күренә башлагач кына үзләренең сугыш барган якларга килеп җиткәннәрен аңлыйлар. Литваның Гайжюнай станциясендә эшелоннан төшереп запасной мотострелковый полкка кушалар. Сугышка керер өчен ныклы әзерлек башлана. 2 ай әзерлектән соң походный марш белән 180 км ераклыктагы Вильнюс шәһәренә китерәләр. Бу вакытта шәһәр фашистлардан азат ителгән, ләкин аннан харәбәләр генә калган, ә фронт әле якында гына була. Бөтен казармалар җимерек, ерак булмаган сазлыкта үлеп ятучы солдатлар да күп була.

Бәзәкәдән бергә чыгып киткән егетләрне барган саен аера баралар. Иң элек Бикмухаметов Шәрифҗанны Ерак Көнчыгыш диңгез флотына аерып җибәрәләр, Зиннатуллин Минерахман Төньяк флотка алына. Шиабиев Зиннур, Шакиров Чингиз дигән егетләрне аерып калдыралар, аннары Мингазов Зиннурны Барановичи шәһәренә күчерәләр. Литвага бергә килгән Кулячев Фоат, Аглиев Зайнак, Хасанов Сабир, Гайнуллин Галимҗан - дүртәү калалар.

Апрель башларында солдатларны Кенигсберг шәһәре астына күчерә башлыйлар. Бер эшелон инде озатыла да. Ләкин аларны юлда бомбага тотып юк итәләр. Бәзәкә егетләре китәргә тиешле икенче эшелонны җибәрмичә

калдыралар һәм Алитус шәһәренә күчерәләр. Соңыннан билгеле булганча, аларны бандеровчылар (“лесные братья”) белән көрәшү өчен монда калдырган булалар. Бандеровчылар белән бәрелешләр еш булып тора, бигрәк тә төннәрен һөҗүм итәләр. Шул бәрелешләр вакытында якташларны да югалталар. Сугыш беткәнче Алитуста хезмәт итәләр. Бөек Ватан сугышы тәмамланганны Зайнак абый нәрәттә торганда ишетә, бу 9 май көненә кадәр була. Ул көнге хәлләрне сөйләп-тасвирлап бетерерлек кенә түгел дип искә ала ветеран.

Сугыш беткәннән соң частьләрне тарата башлыйлар. Өлкән яшьтәгеләрне, врачларны, укытучыларны демобилизовать итәләр. Яшьләрдән үзйөрешле артиллерийский полк төзеп Япония чигенә җибәрү өчен әзерләк башлана, чөнки әле анда сугыш бара. Эшелоннар бер-бер артлы Көнчыгышка юл ала. Безнең егетләргә дә вакыт җитә - аларны да Уралга китерәләр. Аннан Түбән Тагилга күчерәләр, чөнки анда танковый полк бар икән. Шул чакта гына алар Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланганын ишетәләр һәм шул сәбәпле үзләрен кире борганнарын аңлыйлар.

Кулячев Фоат белән Аглиев Зайнакны үзйөрешле артиллерия полкыннан танковыйга күчерәләр. Бу вакытта инде алар авылдашлары Гайнуллин Галимҗан һәм Хасанов Сабир белән аерылган булалар. Хәзер хезмәтне икесе бергә дәвам иттерәләр.

Танковый полкны хуҗалык эшләренә база төзү өчен төрле эшләргә бүлә башлыйлар. Кулячев Фоат пилорамага, Аглиев Зайнак урман кисүгә эләгә. 400 гә якын кеше бер ай дәвамында урман кисә. Норманы үтәгән, югары хезмәт күрсәткечләренә ирешкән солдатларга юлны кертмичә 10 көн ял бирәләр. Бу ялга безнең Зайнак абый да лаек була. Моннан да зур бәхет булуы мөмкинме!? 1946 елның җәендә ул сөенә-сөенә туган ягына юл ала. Можга станциясеннән җәяү кайтырга туры килә аңа. Әле сугыш беткәнгә 1 генә ел үткән, халык һаман кайтмый калганнарны көтә. Юл буе басуда эшләгән хатын-кызлар хәрби киемле Зайнак абый каршына йөгереп чыгалар, үзләренеке турында сорашалар, елашалар.  Кичке аш вакытына, ниһаять, ул Бәзәкәгә кайтып җитә.

10 көн ял сизелмичә дә үтеп китә. Ялдан килүгә полкны расформировать иткәннәр. Зайнак абыйны комиссия үтү өчен Пермьгә җибәрәләр. Шул вакытта алар яңадан Кулячев Фоат  белән күрешәләр. Фоат абыйны строевой хезмәткә яраксыз дип табып хәрби хезмәттән азат итәләр. Ә Зайнак абыйны аерым элемтә ротасына курсант итеп алалар һәм кече командирлар әзерләү курсына җибәрәләр. Шунда укып кече  командир була. Командир отделения, помком радиовзвода, вакытлыча и.о. командира радиовзвода була. Шул вакытта 1927 елгыларны демобилизовать итү башлана. Ләкин бу исемлектә Аглиев булмый. Соңыннан,  офицер вазифасы башкаручыларга хезмәтләрен дәвам итәргә дигән приказ килеп төшә. Һәм аны алга таба хезмәтен дәвам итәр өчен башка частькә урнашкан аерым элемтә  батальонына радиовзвод командиры итеп күчерәләр.

Шулай итеп 1951 елдан башлап Аглиев З. офицер булып хезмәт итә. 1952 елда Дальневосточный военный округ күрсәтмәсенә кергән, Курил

утрауларына урнашкан Парамушир хәрби частенә радио-телеграф пунктының кабул итү-тапшыру начальнигы ярдәмчесе итеп күчерәләр. Шул ук елны “За отличную службу” лейтенант званиесе бирелә.
Служба бара. 4 ноябрь көнне иртәнге сәгать 3 тә Тын океанда, утраудан 150 км ераклыкта 9 баллы җир тетрәү була. Шуның нәтиҗәсендә хасил булган цунами Парамушир утравына утырган 35 мең кеше яшәгән Северокурильск шәһәрен, түбәнлектә урнашкан хәрби частьларны диңгезгә юып алып төшеп китә. Бу көнне Зайнак абый авыру дусты Петровны алыштырып дежурга чыккан була. Менә шул бәхетле очрак нәтиҗәсендә генә ул исән кала. Тау башында исән калган батальоннарга ярдәм итү өчен үзебезнең һәм чит илләрнең корабльләре ярдәмгә җыела. Исән калганнарны материкка күчерү өчен корабльләргә төйиләр. Җыелышып сөйләшкәннән соң утрауда элемтә урнаштыру өчен 20 солдат, 3 сержант, 2 офицер калачак дигән фикергә киләләр. Шул исәптән Аглиев З. – радист, Смирнов – телефонист итеп калдырыла. Чик буенда, җир тетрәп торган Тын океан ярында кыш чыгалар алар. Беренче пароходлар бары тик яз көне генә керә алалар. Үзләрен алыштырырлык белгечләр килгәч утраудагыларны материкка – Южно-Сахалинск шәһәренә кайтарып сәламәтлекләрен тикшереп сорашу үткәрәләр һәм Зайнак абыйны хәрби хезмәттән азат итеп запаска калдыралар (уволен в запас с ограничением срока). Бу 1953 ел була.

Туганнары шушы якларда яшәгәнгә күрә Зайнак абый Пермь шәһәренә кайтып урнаша, заводка токарь булып эшкә керә. Белемгә сусаган егет шундук кичке мәктәптә укый башлый. Сеңлесе Суфия дә шушы шәһәрдә яши. Абыйсы Рәшит гаиләсе белән Воткинскида яши, хәрби заводта эшли. Апасы Мәхмүдә Уралда Губаха шәһәрендә яши. Бары тик Рәшидә апасы гына авылда калган була. Әти-әнисе олы яшьтә булганлыктан Зайнак абый авылга кайтырга карар кыла.

17 яшендә сугышка чыгып киткән яшүсмер Совет Армиясе сафларында тәрбияләнеп, 9 ел Ватанга хезмәт итеп чыныккан ир-егет, офицер булып туган авылына әйләнеп кайта. 10 классны авылда укып бетерә. Эшкә дә мәктәпкә урнаша. Башта кичке мәктәптә 5-7 класс укучыларын физика, математика фәннәрен укыта, аннары көндез укытуга күчә. 1955 елда Казан дәүләт университетының механика-математика бүлегенә укырга керә, 1 елдан соң күңеле кушуы буенча география факультетына күчә. Максатчан, кызыксынучан кеше булганга уку программасын тирәнтен өйрәнә, күп җирләрдә практикада була. Дәресләрендә яшьли күпне күргән кеше буларак, Кенигсбергтан алып Сахалинга кадәр барып чыккан укытучы мавыктыргыч итеп сөйли, укучыларында туган илгә мәхәббәт тәрбияли.

1958 елда Алабуга культура–агарту школасын бетергән Псәй авылы кызы Әнисә белән өйләнешәләр. 1959 елда кызлары Илсөяр, 1968 елда уллары Ильдар туа.

Бәзәкә мәктәбендә 2 ел һөнәри белем бирү буенча директор урынбасары булып эшләгәннән соң 1966 елда Турай мәктәбенә директор итеп күчерәләр. Анда 7 ел эшләү дәверендә мәктәп һәм типовой ашханә төзетә.

1972-1973 уку елында кабат Бәзәкә мәктәбенә тәрбия эше буенча директор урынбасары итеп күчерәләр. 1978 елда директор итеп билгелиләр. Ләкин 1979 елда йөрәк авыруы сәбәпле военрук булып кала.

Минемчә, Бәзәкә мәктәбе тарихына Зайнак абый нәкъ менә военрук буларак кереп кала. Искиткеч оештыру сәләтенә ия булган укытучы балаларны чын патриотлар итеп тәрбияли. Бихисап укучылары, бигрәк тә егетләр, аның дәресләрен яратып искә төшерәләр, дисциплинага өйрәткән остазларына рәхмәт укыйлар. Зайнак абыйның укучыларыннан килгән рәхмәт хатлары, хәрби хезмәттә чакта горурланып формадан төшереп җибәргән фотолары кадерле истәлек булып бүген дә гаилә архивында саклана.

Хезмәтендә ирешкән уңышлары өчен Аглиев Зайнак Аглиевич дәүләт бүләгенә - "За доблестный труд" медаленә, күп санлы грамоталар һәм кыйммәтле бүләкләргә лаек була, фотосы күп еллар дәвамында "Мактау тактасы"нда тора.

1972 елдан коммунистлар партиясе члены Аглиев Зайнак агитатор, пропагандист буларак парткомда идеология буенча зур эш алып бара, политукулар үткәрә. Пенсиягә чыкканнан соң да озак еллар ветераннан советын җитәкли.

Яшьтән кырыс дисциплинага өйрәнгән, һәр эшне зур җаваплылык тоеп башкарган укытучы барысын башкарырга вакыт таба. Югыйсә аның да бит гаиләсе, хуҗалыгы бар.

Бүгенге көндә Зайнак абый белән Әнисә апа балаларының, оныкларының бәхетенә куанып тигез гомер итәләр. Кызлары Илсөяр урта мәктәпне уңышлы тәмамлаганнан соң Казан химия-технология институтын бетерә. Булачак ире Альянс белән дә шунда таныша. Хәзер инде алар үзләре оныклар сөяләр. Кызлары Лилиана Алабуга педагогия һәм Казан авиация институтын тәмамлап Алабуга районы башкарма комитетының беренче урынбасары булып эшләгән. Быел гына Казанга күченгәннәр. Уллары Рамиль Казан авиация институтын бетереп Алабугада ЕлАЗда эшли. Икесенең дә гаиләләре бар.

Ә уллары Ильдар мәктәптән соң армия сафларында хезмәт итә, Кама машина төзүчеләр техникумын тәмамлый. Хатыны Эльмира белән бүгенге көндә Алабугада яшиләр, 2 ул тәрбияләп үстергәннәр. Икесе дә Ижевск шәһәрендә юристлыкка укыйлар: Марат – IV- курста, Ильмир – I-курста.

Бүгенге көн, яшьләр турында сез ни уйлыйсыз дигән соравыма гомерен балалар тәрбияләүгә биргән педагог болай дип җавап бирде: "Хәзерге яшьләр техниканы бик яхшы беләләр, әмма гомуми үсеш бик түбән, бүгенге көн белән яшиләр, киләчәк өчен кайгырмыйлар. Элек армиягә баручылар дәрәҗәле иде, соңыннан армиянең дәрәҗәсе төште. Менә соңгы елларда гына армиянең дәрәҗәсе күтәрелә башлады. Патриотик тәрбия турында күп сөйлиләр, әмма, патриотик тәрбия – ул хәрби хезмәт, ватанны ярату гына түгел, ул шул Ватан хакына хезмәт тә. Һәркем үз урынында намуслы хезмәт итәргә тиеш".

Хөрмәтле ветеран бүгенге көненнән бик канәгать. Янында гомер иткән хатыны бар. Балалары, оныклары һәрдаим кайтып аралашып торалар. Ул шуңа шөкер итеп яши.

Зайнак абый белән якыннан аралашкач мин аның никадәр тыйнак, сабыр кеше булуын аңладым. Бер генә тапкыр зарланмады да, үкенмәде дә. Югыйсә аның да балачагы уен уйнап кына узмаган – яшьтәшләре белән буразна арасында үткән, үсмер чагы сугыш елларына туры килеп зурлар белән беррәттән колхозда эшләгән. Инде үз тормышын коргач та гомер юлы аныкы гына такыр юлдан тәгәрәмәгәндер. Әмма бу көчле шәхес гомере буе Аллаһы Тәгалә биргән талантын, сәләтен акыл белән кулланып Ватанына хезмәт иткән. Сокланырлык та, горурланырлык та, үрнәк алырлык та кеше янәшәбездә яши.

Ф.Башарова. (апрель 2017 ел)